СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ КАРАР**

2024 елның 4 октябре № 22

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 23 октябрендәге 46 номерлы карарына (15.10.2018 № 18, 29.11.2018 № 24, 01.03.2023 № 2, 10.04.2023 № 13 үзгәрешләр белән)үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 23 октябрендәге 46 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 1 августындагы 20 номерлы карарын (15.10.2018 ел, № 18, 29.11.2018 № 24, 01.03.2023 № 2, 10.04.2023 № 13 үзгәрешләр белән)үз көчен югалткан дип танырга.

2.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 23 октябрендәге 46 номерлы карарына (15.10.2018 № 18, 29.11.2018 № 24, 01.03.2023 № 2, 10.04.2023 № 13 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның 1 пунктчасындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук салым салу объектларында урнашкан гаражларның һәм машина урыннарының кадастр бәясе аларның һәрберсенә 300 миллион сумнан артык»;

б) карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасының 4 абзацын төшереп калдырырга;

в) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектлары исемлегенә кертелгән салым салу объектларына карата 2025-2027 еллар салым чорларына 1,2 процент һәм 2028 елдан башлап алдагы салым чорларына 2 процент салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган;

Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2025 елга 2 процент һәм 2026 елдан башлап алдагы салым чорына 2,5 процент.».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан җирлекнең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урам, 105 йорт буенча административ бинада, Совет урамы, 8 йорт буенча балалар бакчасы бинасында, Мельничная урамы , 23 йорт, Югары Чыршылы авылы ФАП бинасында, Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановка авылы, Совет урамы, 13 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

"Түбән Чыршылы авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе — Н.Я.Хәйруллина